| Совет Старошаймурзинского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советы |
|---|---|

Иске Шәйморза

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12 август 2021 ел №11/1

"Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»карар проекты хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Җир кодексы, «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 07.07.2003 елдагы 112-ФЗ номерлы Закон нигезендә, прокурор протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының 25.01.2014 ел, №34/1 карары (12.04.2019, №48/3; 31.05.2021, № 8/1;25.02.2021 №5/2 редакциясендә) белән расланган "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертәргә:

1) **16 статьяның 1 пунктында** «капиталь төзелеш» сүзләреннән соң «мондый рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән алып унбиш эш көне эчендә әзерләнә»сүзләрен өстәргә:;

2) **30 статьяда:**
а) **2 пунктка** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"6) территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул итү.»;
б) **6 пунктта** «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн»сүзләренә алмаштырырга.;

3) **36 статьяның 8 пунктындагы** дүртенче абзацын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән алмаштырырга; :
«Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану илнең оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану һәм саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яки тыелырга мөмкин.

Территорияләрне файдалану өчен махсус шартлары булган торак пунктлар һәм зоналар территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану халыкның тормыш һәм сәламәтлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау, биналар һәм корылмаларның сакланышы, шул исәптән тау эшләнмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле башка корылмаларның сакланышы куркынычын тудыра алган очракларда чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.

Аеруча саклана торган табигый территорияләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану аларның территорияләрен махсус саклау режимы нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» гы карар проекты буенча ачык тыңлаулар 28.06.2021ел №9/1 “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турындагы Нигезләмә” нигезендә, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Шәйморза авылы, Ленин урамы, 63 нче йорт адресы буенча 2021 елның 11 ноябренә сәгать 10 да билгеләргә.

3. Карар проектындагы материаллар белән: - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге порталында Sshm -drogganoe.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы рәсми порталы»дәүләт мәгълүмат системасы составында (Иске Шәйморза авыл җирлеге).

- авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында: Иске Шәйморза авылы, Ленин урамы, 63 нче йорт, Ленин урамы, 61 нче йорт, танышырга мөмкин.

4. Әлеге карар проекты буенча гражданнарның искәрмәләре һәм тәкъдимнәре 2021 елның 10 ноябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Шәйморза авылы, Ленин урамы, 63 нче йорт.

5. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Иске Шәйморза авылы, Ленин урамы, 63 нче йорт, Ленин урамы, 61 нче йорт,

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Шәйморза авыл җирлеге башлыгы: И.Д.Мөхитова